ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге составына керүче Сикәнәс торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 3 «25» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Сикәнәс торак пунктында 2023 елның «25» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Сикәнәс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары 2024 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Секинес торак пунктында Заречная, Мәктәп урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш, ком җәю, кырдырып тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Сикәнәс торак пунктында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сикәнәс торак пунктында юлларны кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 96 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 64 кеше, 66,7 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 64 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Сикәнәс торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Сикәнәс торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Сикәнәс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 2024 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Секинес торак пунктында Заречная, Мәктәп урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш, ком җәю, кырдырып тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Сикәнәс торак пунктында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сикәнәс торак пунктында юлларны кардан чистарту;

3. Әлеге карарны Омар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Чернов